РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Урсаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 60, Азнакаевский район,
с.Урсаево, 423318,
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 60 нчы йорт, Азнакай районы,
Урсай авылы, 423318
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «08» ноябрь 2024г.** **№ 6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. «Сез 2025 елда Урсай авыл җирлеге Мөслим авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан,хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзәләреннән, көндезге уку формасында укучылардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
   - су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылында авария хәлләрен бетерү, торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу);
   - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мөслим авылында гравий түшәмәсе урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Мөслим авылы юлларын кардан чистарту);

«ЗА» «ПРОТИВ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм җирлекнең рәсми сайтына кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә

Башлык З.Х.Рахимьянова